**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 24.11.2020** **№ 891**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 667 номерлы «2020 - 2021 уку елында Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы «2021 елга айлык акчалата һәм башка түләүләрнең күләме турында» карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 октябрендәге 908 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай тукландыру белән тәэмин итүгә һәм аны оештыруга норматив чыгымнарны раслау турында» карарын үтәү йөзеннән, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 667 номерлы «2020 - 2021 уку елында Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның өченче абзацында «7,70» саннарын «8,00» санына алыштырырга;

2) 2 пунктта «51,85» саннарын «53,41» саннарына алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин